КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 ноябрь г.Казань № 963

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 915 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 30 декабрь, 1097 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1096 нчы; 2015 ел, 6 ноябрь, 325 нче; 2015 ел, 12 ноябрь, 847 нче; 2016 ел, 1 март, 127 нче; 2016 ел, 4 июнь, 372 нче; 2017 ел, 12 май, 276 нчы; 2017 ел, 29 июль, 529 нчы; 2017 ел, 28 август, 609 нчы; 2018 ел, 18 июнь, 493 нче; 2018 ел, 12 сентябрь, 773 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1218 нче; 2019 ел, 7 сентябрь, 800 нче; 2019 ел, 16 декабрь, 1154 нче; 2020 ел, 25 август, 731 нче; 2020 ел, 9 октябрь, 915 нче; 2020 ел, 25 декабрь, 1192 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 811 нче; 2021 ел, 25 сентябрь, 914 нче; 2022 ел, 22 гыйнвар, 38 нче; 2022 ел, 17 май, 452 нче; 2022 ел, 27 июнь, 611 нче; 2023 ел, 15 апрель, 471 нче; 2023 ел, 1 август, 927 нче; 2023 ел,

30 август, 1041 нче; 2023 ел, 10 октябрь, 1290 нчы; 2023 ел, 2 декабрь, 1548 нче; 2024 ел, 17 гыйнвар, 17 нче; 2024 ел, 14 февраль, 79 нчы; 2024 ел, 13 сентябрь, 784 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарын һәм социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр күрсәтә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәгә, 53 нче таблицаның «Социаль хезмәт күрсәтү комплексłы үзәкләренең өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасы белән бүлекләр һәм социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасы белән гаиләләргә һәм балаларга ярдәм бүлекләре» юлының «601,0дан һәм аннан югары» өстәмә юлындагы 3 графасында «0,570» саннарын «0,542» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин